ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

_____29.04.2020_________ Казан шәһәре № ____42____

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 31 маендагы 62 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук үзләренә карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм(яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзелешенә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актын федераль законнарга яраштыру максатларында,

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 31 маендагы 62 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 19 сентябрендәге 105 номерлы, 2020 елның

21 февралендәге 11 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук үзләренә карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм(яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзелешенә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2020 елның 29 апрелендәге 42 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 31 маендагы 62 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук үзләренә карата «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм(яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган Татарстан Республикасының аерым муниципаль берәмлекләрендә торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзелешенә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №1, 1 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, 14 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №44, 4147 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, 40 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №19, 2060 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау

турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №31, 3451 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Торак төзелешен үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 161-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №30, 3617 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №1, 26 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Төзүче оешмалар бөлгенлеккә төшкәндә (банкрот булганда) гражданнар – өлешле төзелештә катнашучылар хокукларын яклау буенча гавами-хокук компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 218-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017 елның 31 июле, №31 (1 өлеш), 4767 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документларының бүлекләре составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 87 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №8, 744 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №19, 2825 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 №17, 2418 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый

кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, №8, 1239 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашу килешүе нигезендә күпфатирлы йортлар төзү (булдыру) өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчасын җәлеп итү хокукына ия булган төзүче оешманың шәхси акчасын исәпләү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 11 июнендәге 673 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 2018 елның 11 июнендәге 673 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, №25, 3693 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы сайты адресын билгеләү турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 1133 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, №40, 6137 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче оешма эшчәнлегенең финанс тотрыклылык нормативлары турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 28 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201812280060, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы турында» 2019 елның 26 мартындагы 319 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 319 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 28 март, басылып чыгу номеры: 0001201903280008, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

РФ Хөкүмәтенең «2020 елда дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында һәм дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләренең 7 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 3 апрелендәге 438 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы(www.pravo.gov.ru), 2020, 6 апрель, бастылып чыгу номеры: 0001202004060044, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек (күзәтчелек) органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм

(яисә) мәгълүматлар исемлеге (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, №18, 2647 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект декларациясе рәвешен раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы (алга таба – 996/пр номерлы Россия Төзелеш министрлыгы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, http://pravo.gov.ru, 2016, 30 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201612300099, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзелеше өчен гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән мондый кооператив тарафыннан кооператив әгъзалары һәм башка затлар каршындагы үз йөкләмәләренең үтәлеше турында хисаплылык формасын һәм торак-төзелеш кооперативы тарафыннан әлеге хисаплылыкны күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органына тапшыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 3 июлендәге 955/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 955/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 27 октябрь, кертелгән үзгәрешләр исәпкә алып);

РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве турында бәяләмә формасын раслау турында» 2018 елның 11 октябрендәге 653/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 653/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 28 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201812280059, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзүче оешмалар тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзелеш проектларын һәм килешүләр буенча үз йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеген гамәлгә ашыруның якынча графикларын үтәү турында

хисаплылык формасын һәм контрольдә тотучы органга тапшыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2019, 21 февраль, басылып чыгу номеры: 0001201902210040, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Акчалардан максатчан файдалану йөкләмәләрен һәм нормативын тәэмин итү нормативын исәпләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 15 маендагы 278/пр номерлы боерыгы Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 23 июль, басылып чыгу номеры: 0001201907230002);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары тарафыннан төзүче оешмадан инженерлык эзләнүләре, архитектура-төзелеш проектлары уздыру һәм төзелеш буенча эшләрне башкаручы, товарлар китерүче һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүче затлар турында, шулай ук мондый торварларның, эшләрнең, һәм хезмәтләр күрсәтүнең төрләре турында мәгълүмат һәм әлеге затларның күрсәтелгән эшләр төрен башкаруга, товарлар китерүгә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тиешле рөхсәтләре (лицензияләре) булуы турында мәгълүмат алу тәртибе турында» 2019 елның 18 декабрендәге 820/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2020, 23 март, басылып чыгу номеры: 0012020003230049);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзүче оешмалар тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъекты башкарма органына күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шулай ук төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларын һәм килешүләр буенча үзләренең йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеген үтәү турында хисаплылык тапшыру үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2020 елның 3 апрелендәге 187/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2020, 17 апрель, басылып чыгу номеры: 0001202004170030);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъекты башкарма органына торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан күпфатирлы йортлар төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген гамәлгә ашыру, шул исәптән мондый кооперативлар тарафыннан кооперативларның әгъзалары һәм башка затлар каршындагы үз

йөкләмәләрен үтәве турында хисаплылык тапшыру үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2020 елның 10 апрелендәге 204/пр номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2020, 20 апрель, басылып чыгу номеры: 0001202004200042);

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 66-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, 2007, 28 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2007, № 43, 1707 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзелешенә төзелеш өчен гражданнардан акча җәлеп итүче затлардан, торак-төзелеш кооперативыннан һәм мондый кооператив күпфатирлы йорт төзелешенә бәйле килешүләрне төзегән башка затлардан алына торган гражданнар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр, мәгълүматлар һәм (яки) документлар исемлекләре турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, №77, 2609 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 31 октябрендәге 974 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, №89, 2905 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (төзү) өчен өлешләп төзүдә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затларга карата гамәлгә ашырыла:»;

1.6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) хезмәт таныклыгын һәм тикшерү уздыру турында Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсенең күчермәсен күрсәтеп, күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затлар эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урыннарга алар тарафыннан мәҗбүри таләпләр үтәлешен тикшерү максатларында каршылыксыз үтеп керергә;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) тикшерү уздырылуы турында боерык (күрсәтмә) кабул ителгәннән соң күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затлардан кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга, урынга чыгып тикшерү уздырганда тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документларны алырга, әгәр мондый документлар күчмә тикшерү алдыннан узган документар тикшерү вакытында күрсәтелмәгән булса;»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

9) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затлардан телдән яки язмача аңлатмалар алырга;»;

егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 «күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затлар тарафыннан шикаять белдерелгән очракта, үз гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расларга;»;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда вазыйфаи затларның бурычлары:

1) зарури таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм чикләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкару;

2) Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау;

3) Инспекция башлыгының (башлык урынбасарының) тикшерү уздыру турындагы күрсәтмәсе нигезендә аның билгеләнүе нигезендә тикшерү уздыру;

4) тикшерүне фәкать хезмәт вазыйфаларын үтәү вакытында гына, урынга чыгып тикшерүне фәкать хезмәт таныклыкларын, Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) күрсәтмәсе күчермәсен күрсәтеп кенә уздыру;

5) күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә тикшерү уздырганда катнашырга һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә комачауламау;

6) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын

төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затның тикшерү уздырганда катнашкан җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына караган мәгълүматларны һәм документларны бирү;

7) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле затын тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;

8) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле затын ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән таныштыру;

9) ачыкланган хокук бозу фактлары буенча күреләчәк чараларны билгеләгәндә әлеге чараларның җитешсезлекләрнең авырлыгына, аларның гражданнар, юридик затлар өчен потенциаль хәтәренә туры килүен исәпкә алу, шулай ук гражданнарның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез рәвештә чикләнүгә юл куймау;

10) күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затлар тарафыннан шикаять белдерелгән очракта, үз гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә раслау;

11) 294-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тикшерүне үткәрү срокларын үтәү;

12) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затлардан Россия Федерациясе законнарында каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәү;

13) урынга чыгып тикшерү уздыра башлар алдыннан, күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле затының гозере буенча, аларны тикшерү уздыруга нигез булган әлеге Регламент нигезләмәләре белән таныштыру;

14) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затта булган очракта, уздырылган тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу теркәү.»;

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары» бүлегенең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затларның хокуклары һәм бурычлары»»;

1.10 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затларның бурычлары:»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) урынга чыгып тикшерү уздыруда катнашучы вазыйфаи затларга күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затлар тарафыннан кулланыла торган территориягә (бинага, төзелмәгә, корылмага, бинага) үтеп керүне тәэмин итү;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вазыйфаларга ия була ала.»;

2 бүлектә:

2.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру мәсьәләләре, шулай ук Инспекциянең урнашкан урыны һәм эш графигы турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:»;

2.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Инспекциянең урнашу урыны, эш графигы, телефон номерлары һәм факс номерлары, дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат бирә ала торган вазыйфаи затларның электрон почта адресы турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат);»;

2.12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Регламентның 2.14-2.16 пунктларында каралган нигезләр буенча тикшерүләр уздырылганда РФ Хөкүмәтенең «2020 елда дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында һәм дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләренең 7 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 3 апрелендәге 438 номерлы карарында күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук 2020 елга күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру үзенчәлекләре билгеләнгән.»;

2.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.17. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәге вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Инспекция башлыгы;

2) Инспекция башлыгы урынбасарлары;

3) Бүлек башлыгы;

4) Бүлекнең әйдәүче консультанты;

5) Бүлекнең өлкән белгече.»;

5 бүлектә:

5.83 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.83. Хисаплылык төзүче оешма һәм торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Инспекциягә хисап кварталы тәмамланганнан соң утыз календарь көне узганчы тапшырыла, IV квартал өчен хисаплылыктан тыш, анысы төзүче оешма тарафыннан – IV квартал тәмамланганнан соң туксан календарь көне узганчы, ә торак-төзелеш кооперативы тарафыннан алтмыш календарь көне узганчы тапшырыла. Шул ук вакытта хисаплылыкны тапшыру датасы булып төзүче оешма, торак-төзелеш кооперативының шәхси кабинетында торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында хисапларны урнаштыру датасы тора.

Төзүче оешма һәм торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Инспекциягә 2019 елның IV кварталы һәм 2020 елның 1 кварталы өчен хисап тапшыру 2020 елның 1 июненә кадәр гамәлгә ашырыла.

Төзүче оешма тарафыннан хисаплылык, хисап чоры дәвамында өлешле төзүдә катнашучы белән төзүче оешма тарафыннан төзелгән өлешле төзүдә катнашу турында бер генә килешү булса да гамәлдә булган очракта яки төзүче оешманың өлешле төзүдә катнашу турындагы килешү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булган очракта, Инспекциягә квартал саен тапшырыла.

Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан хисаплылык Инспекциягә төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йорт составында беренче килешү төзелгән кварталдан башлап квартал саен һәм күпфатирлы йортны файдалануга тапшыру өчен рөхсәт алынган квартал буенча тапшырыла.

Төзүче оешма тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашучылар акчасын җәлеп иткәндә, 214-ФЗ номерлы федераль законның 15.4 статьясында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, мондый чараларны эскроу счетларында урнаштыру юлы белән, Инспекциягә хисаплылык тапшырылмый.

Әгәр өлешле төзелеш объектларының бер өлешенә карата бер төзелеш проекты составында төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының 4 өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла икән, ә әлеге төзелеш проекты составында башка өлешле төзелеш объектларына карата төзүче оешма тарафыннан өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итү 214-ФЗ номерлы федераль законның 15.4 статьясында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырылса, хисаплылык төзүче оешма тарафыннан Инспекциягә бары тик 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының 4 өлеше нигезендә төзелгән өлешле төзелештә катнашу килешүләренә карата гына тапшырыла.»;

5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентка

№ 5 кушымта

**Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге***

1. Инспекция башлыгы;
2. Инспекция башлыгы урынбасарлары;
3. Бүлек Башлыгы;
4. Әйдәп баручы консультант;
5. Бүлекнең өлкән белгече.

* Исемлектә күрсәтелгән Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 28.3 статьясында, асылда Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 13.19.2 статьясының 1 өлешендә (күпфатирлы йортларны төзүне гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 13.9.3 статьясында (төзүче оешма, төзүче оешманың вазыйфаи затлары тарафыннан кылынган административ хокук бозулар өлешендә), 14.28 статьясының 1-5 өлешләрендә, 14.28.1 статьясында һәм 19.5 статьясының 4 өлешендә, 20.25 статьясының 1 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә хокуклы.».